# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2025 2 (46)

ISSN 2499-9741

КАЗАН

***Журнал «Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан нәшер ителә.***
***Елына кәгазь һәм электрон форматта 4 сан чыгарыла.***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе

► **РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, редколлегия рәисе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МИҢНЕХАНОВ Р.Н., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХАЛИКОВ И.И., филология фәннәре кандидаты (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ МӨХӘРРИР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
НАДЫРШИНА Л.Р., ГЫЙНИЯТУЛЛИНА Л.М. (җаваплы сәркатип)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ДӘҮЛӘТШИНА Л.Х. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
АБДУЛЛИНА Н.Т., ЧУГУНОВ А.С.

Редакция адресы: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһ., К. Маркс ур, 12.
ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Тел.: (843) 590-61-11
E-mai1: f_tatarstan@mail.ru
Сайт: https://ft.antat.ru/

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Гыйләҗетдинова Г.Х.* XV–XVII гасырлар рус телендәге Көнчыгыш алынмалары сүзлеген оештыру үзенчәлекләре . . . . .7
*Хәбибуллина Л.Г.* Татар телендә иярчен җөмлә төрләре . . . . . . .15
*Хисияма Ю.* Соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларында сингармонизм күренеше: Татар теленең язма корпусы нигезендә тикшеренүләр . . . . . . .21
*Идиятуллина А.И., Хөсәинова А.Я.* Татар теленең метеорологик лексикасын өйрәнү тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .29

### ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ФӘНЕ

*Алишина Х.Ч.* Элгәрләребезнең фәнни мирасы: тюрколог, борынгы уйгур теле белгече профессор Д.М. Насиловның тууына 90 ел тулу уңаеннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .34

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Юсупова Н.М.* Кәшшаф Патии: шагыйрь, укытучы, мулла . . . . .46

### ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛЛЫКНЫ КАРШЫЛАП

*Заһидуллина Д.Ф.* Фатих Әмирхан: татар халкы өчен янып яшәү. .53
*Хөснетдинова Г.А.* Халык мәнфәгатен яклап.... . . . . . . . . . . .66

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Дәүләтшина Л.Х.* Татар йола фольклорының бүгенге яшәеше: солдатка озату йоласы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .77

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Абзалина Р.Ә.* Күңел матурлыгын сурәтләрлек пумалалар бармы дөньяда?.. *(К. Насыйри портретын ясау тарихы)*. . . . . . . . . .88

### БӨЕК ҖИҢҮГӘ 80 ЕЛ

*Дәүләтшин Г.М.* Г. Фронт һәм фән юлын узган галимнәр . . . . .95
*Фазлетдинов И.К.* Башкортстан татарларының бәетләрендә Бөек Ватан сугышы вакыйгалары чагылышы . . . . . . . . . . . 110

### СӘНГАТЬ

*Шевченко Е.Н.* Коки Митаниның «Көлке академиясе» Айдар Җәббаров куелышында. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
*Галиева Р.Н.* 1920 еллар татар плакатларының визуаль теле һәм пластик чишелеш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . 125
*Шкляева Л.М., Герасимова Н.В.* Ф.Г. Халиков иҗатында тарихи жанр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133

**ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН**

*Гайнетдинов А.М.* Самара өлкәсе Камышлы районының эпиграфик мирасы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Фәйзрахманов Җ.И.* Фәнгә яңалык кертүче *(профессор Ф.С. Сибәгатуллинның фәнни мирасы)* . . . . . . . . 145

*Закирова И.Г.* Фольклорчы Флора Әхмәтова-Урманче . . . . . . 150

*Бәширова И.Б.* «Әдәби тел тарихы – аның стильләре тарихы» *(Латыйф Җәләйнең туууына 130 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . 155

*Ямалтдинов И.И.* Татар җырларын өйрәнүгә багышланган гомер *(фольклорчы Илбарис Надировның тууына 100 ел)* . . . . . . . . 169

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Ильина Г.Г.* Татарларның дөньяны мифологик кабул итүе: төп образлар һәм символлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ


*Гилязетдинова Г.Х.* Особенности организации словаря восточных слов в русском языке XV–XVII веков . . . . . . . . . . .7

*Хабибуллина Л.Г.* Виды придаточных предложений в татарском языке. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .15

*Хисияма Ю.* Проявление сингармонизма в арабско-персидских заимствованиях с гласным [и] в конечном слоге: исследования на основе Письменного корпуса татарского языка. . . . . . . . . .21

*Идиятуллина А.И., Хөсәинова А.Я.* История изучения метеорологической лексики татарского языка . . . . . . . . . . . . .29


## НАУКА ТЮРКСКИХ НАРОДОВ


*Алишина Х.Ч.* Научное наследие предшественников: к 90-летию тюрколога, специалиста по древнеуйгурскому языку профессора Д.М. Насилова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .34


## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ


*Юсупова Н.М.* Кашшаф Патии: поэт, педагог, имам-хатыб . . . . .46


## К 140-ЛЕТИЮ ФАТИХА АМИРХАНА


*Заһидуллина Д.Ф.* Фатих Амирхан: жизнь во имя татарского народа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .53

*Хуснутдинова Г.А.* На защите интересов народа... . . . . . . . . . .66


## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО


*Давлетшина Л.Х.* Современное бытование обрядового фольклора татар: обряд проводов в армию . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .77


## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ


*Абзалина Р.А.* К истории создания портрета К. Насыри . . . . . . .88


## 80 ЛЕТ ВЕЛИКОЙ ПОБЕДЕ


*Давлетшин Г.М.* Ученые-фронтовики ИЯЛИ . . . . . . . . . . . . . .95

*Фазлутдинов И.К.* Отражение событий Великой Отечественной войны в баитах татар Башкортостана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110


## ИСКУССТВО


*Шевченко Е.Н.* «Академия смеха» Коки Митани в постановке Айдара Заббарова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119

*Галиева Р.Н.* Особенности визуального языка и пластических решений татарских плакатов 1920-х гг. . . . . . . . . . . . . . . . . . 125

*Шкляева Л.М., Герасимова Н.В.* Исторический жанр в творчестве Ф.Г. Халикова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133

## ПО СЛЕДАМ НАУЧНЫХ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Гайнутдинов А.М.* Эпиграфическое наследие Камышлинского района Самарской области . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139

## ПЕРСОНАЛИИ

*Файзрахманов Дж.И.* Научное наследие профессора Ф.С. Сибагатуллина . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145

*Закирова И.Г.* Фольклорист Флора Ахметова-Урманче . . . . . . 150

*Баширова И.Б.* Об истории стилей татарского литературного языка *(к 130-летию со дня рождения Латифа Заляя)* . . . . . . 155

*Ямалтдинов И.И.* Исследователь татарской песенной поэзии *(100 лет со дня рождения фольклориста Ильбариса Надирова)* . 169

## НОВЫЕ КНИГИ

*Ильина Г.Г.* Мифологическое мировосприятие татар: ключевые образы и символы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 75.05

***Л.М. Шкляева,***
***Н.В. Герасимова***

# Ф.Г. ХАЛИКОВ ИҖАТЫНДА ТАРИХИ ЖАНР

В данной статье рассматриваются творческие работы живописца Фирината Халикова, посвященные истории татарского народа XVI века. В результате применения иконологического и семантического методов исследования авторы приходят к выводу, что художник убедительно, в академической манере, изображает реальные исторические события, однако интерпретирует их в трагическом и отчасти романтическом аспектах. Масштабные полотна привлекают внимание выразительностью художественных приемов – умелым использованием контрастов не только цветовых, но и тональных отношений. Создавая на полотнах образы ушедшей эпохи, автор не стремится к документальной достоверности, но уделяет главное внимание воплощению идеи сопричастности своих героев судьбе Родины, воспевает их мужество и стойкость. Материал исследования основан на произведениях художника, хранящихся в коллекциях Государственного историко-культурного и художественного музея-заповедника «Казанский Кремль» и Государственного музея изобразительных искусств Республики Татарстан.

**Ключевые слова:** живописные произведения, исторические сюжеты, Казань, Ф.Г. Халиков.

This article examines the creative works of the artist Firinat Khalikov, dedicated to the history of the Tatar people of the 16th century. As a result of applying icono logical and semantic research methods, the authors come to the conclusion that the artist convincingly, in an academic manner, depicts real historical events, but interprets them in tragic and partly romantic aspects. Large-scale canvases attract attention with the expressiveness of artistic techniques – the skillful use of contrasts of not only color, but also tonal relationships. Creating images of a bygone era on canvases, the author does not strive for documentary authenticity, but pays main attention to the embodiment of the idea of his heroes' involvement in the fate of the Motherland, glorifies their courage and fortitude. The research material is based on the artist's works stored in the collections of the State Historical, Cultural and Art Museum-Reserve "Kazan Kremlin" and the State Museum of Fine Arts of the Republic of Tatarstan.

**Keywords:** paintings, historical subjects, Kazan, F.G. Khalikov.

Хәзерге вакытта сынлы сәнгатьтә тарихи сюжетларны реалистик гәүдәләндерү бик тә актуальләште. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: совет чорында бу жанрга Б.И. Урманче (1897–1990), Х.Ә. Якупов (1919–2010) һәм башка танылган татар рәссамнары еш мөрәҗәгать итә. Бигрәк тә Бакый Урманче картиналары игътибарга лаек. Аның әсәрләренең күптөслелелеккә корылган чишелешендә, яссы сурәтләү манерасында һәм силуэтларының түгәрәк дулкынсыман

салмак сызыкларында Шәрык сәнгатенә хас алымнар ярылып ята. Харис Якуповның эшләрендә социалистик реализм билгеләре – монументальлек һәм героик образларны гиперболаштыру, көчләрнең идеологик күзлектән дөрес конфликты ачык чагыла. Зур рәссам иҗатына хас әлеге алымнарны шәкерте Ф.Г. Халиков та (1957) актив үзләштерә.

Бүгенге көндә Фиринат Габделхәй улы Халиков – Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), Россия Сәнгать академиясе академигы (2020) һәм, академик реализм традицияләренә тугрылыклы булып, Татарстанда тарихи жанрга караган тематик картиналар остасы. Үзенең «Казан өчен сугыш» (1996), «Олуг Мөхәммәд» (2003) һ. б. әсәрләрендә ул еш кына татар халкының үткәндәге героик сәхифәләренә дан җырлый. Бу полотноларның шактый өлеше «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музейтыюлыгы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее тупланмаларында саклана.

Казанда рәссамның беренче шәхси күргәзмәләре оештырыла башлаганнан бирле (1997), Татарстан сәнгать белгечләре Ф.Г. Халиков әсәрләре белән даими кызыксыналар. Мәсәлән, Р.Г. Шаһиева аның иҗатын колачлаган ике альбомга язган кереш мәкаләләрендә (2005, 2017) Казан ханлыгының үткәнен сурәтләгәндә аның матур сәнгати чаралар белән эш итү сәләтен ассызыклап күрсәтә, әйтерсең рәссам үзе дә әлеге вакыйгаларның шаһиты булган [5; 4]. «В его многофигурных полотнах и исторических пейзажах зрители увидели затерянное в анналах истории Казанское ханство, её строительную мощь и цельность, крепости, мечети, ханские дворцы, посады, колоритные базары и типажи легендарных казанцев» [5: 50].

Алдагы альбом (2012) бүлекләренең авторлары – Д.К. Вәлиева, Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова, О.Л. Улемнова, Д.Д. Хисамова һ. б. сәнгать белгечләре, Ф.Г. Халиков иҗатының әһәмиятен бәяләп, автор манерасының индивидуальлеген, кабатланмаслыгын, катлаулылыгын ассызыклыйлар. «Күпфигуралы эскизларында һәм пейзажларында ул теманы өйрәнә, композицияләр төзи, детальләрне барлый» [1: 174].

Безнең тикшеренүдә төп игътибар Ф.Г. Халиковның 1980–2005 елларда язылган һәм Казан ханлыгын яулап алу тарихына бәйле картиналарына, XX гасыр ахыры һәм хәзерге заман тамашачыларының аларны ничек кабул итүенә юнәлтелгән.

А.А. Рылов исемендәге Вятка сәнгать училищесында махсус белем алып, Ф.Г. Халиков Казан шәһәрендә Россия Сәнгать академиясенең иҗат остаханәләренә алына (1993), анда академик Х.А. Якупов җитәкчелегендә Көнбатыш Европа һәм рус сынлы сәнгатенең классик кануннарын үзләштерә. Рәссам төрле жанрларда картиналар яза – еш кына замандашларының портретларын иҗат итә яисә балачагы һәм яшьлеге үткән Киров өлкәсе авыллары пейзажларының кырыс

матурлыгын тасвирлый. Әмма 1990 еллар уртасыннан алып 2000 еллар башына кадәр аның иҗатында үзәк урынны нәкъ менә тарихи жанр алып тора. Бу шуның белән дә аңлатыла: аның остаханәдә белем алу чоры үзгәртеп корудан соңгы елларга туры килә, бу вакытта республика җәмәгатьчелегенең күп кенә вәкилләрен татар халкының милли үзенчәлеге һәм тарихи үткәне белән бәйле мәсьәләләр борчый. Әлеге темалар яшь рәссамның да игътибарын җәлеп итә, иҗатын колачлап ала һәм авторның дөньяга үзенчәлекле карашын да чагылдыра. Рәссам тарихи вакыйгаларны ышандырырлык итеп сурәтли, әмма еш кына аларны фаҗигалы аспектта интерпретацияли. Моңа ирешүдә бөтен сәнгать алымнарын эшкә җигә.

Ф.Г. Халиков XVI гасыр Казан ханлыгы язмышы белән бәйле темаларга мөрәҗәгать итә. Рәссам үзенең полотноларында татар мәдәнияте өчен гаять әһәмиятле, инде 500 елдан артык дан да җырланган, гаепләнгән дә героик образларны гәүдәләндерә. Ул иҗат иткән масштаблы тарихи әсәрләр Татарстанның фән, сәнгать һәм сәясәт эшлеклеләре арасында шунда ук танылу ала.

Киндердә башкарылган эшләрендә Ф.Г. Халиков Казан ханлыгы халкының төрле катлауларын сурәтли. Аларны охшаш хис-кичерешләр берләштерә – я каршылык күрсәтү («1552 елгы октябрь вакыйгасы» һ. б.), я югалту («Сөембикәнең хушлашуы» һ. б.). Моннан тыш, рәссам үзенең картиналарында Казан ханлыгы корылмаларын да торгыза. Кирпеч-таштан салынган Хан Кирмәне биналарының һәм бистәдәге агач йортларның реконструкцияләрен ул А.Х. Халиков (1994) [2], Ф.Ш. Хуҗин (2005) [3] кебек күренекле галимнәрнең материалларына таянып эшли.

Ф.Г. Халиков, тарихи жанр традицияләрен дәвам итеп, Татарстан сынлы сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертте. Татар тарихының героик һәм бер үк вакытта фаҗигалы образларын тудырып, Татарстанның хәзерге заман рәссамнары арасында үзенең мәртәбәле урынын алды. Рәссам чынбарлыкта булган вакыйгаларны торгызырга омтыла, ул моңа, күтәрелгән теманың өйрәнелү дәрәҗәсе биргән мөмкинлектән чыгып, сурәтнең тарихи масштаблылыгын тормыш-көнкүрештәге дөреслек белән берләштерү аша ирешә. Аның тарихи әсәрләре арасында оста башкарылуы һәм хисси киеренкелекне бирә алуы белән «Колшәриф мәчете янында соңгы сугыш» (2005), «Сөембикәнең хушлашуы» (2001) картиналары аерылып тора.

«Колшәриф мәчете янында соңгы сугыш» полотносында Ф.Г. Халиков 1552 елда Явыз Иван гаскәрләре Кремльне алгандагы сугышны сурәтли, киндердә аның кульминациясендәге киеренкелекне гәүдәләндерүгә ирешә. Шул ук вакытта якларның каршы торуы шундый итеп күрсәтелә ки, тамашачы сугыштан читкә чыга торган вакыйгаларның алга таба үсешен фаразлый ала. Рәссам Мәскәү патшасының күпкә өстен хәрби көчләренең тиздән җиңүгә ирешәчәген һәм Кремльдәге Хан мәчете имамы Кол Шәрифнең шәкертләре белән

бергә һәлак булачагын алдан сиземләүне тамашачыга җиткерә. Сугыш панорамасы янгын шәүләләре һәм ялкынның кызыл телләре белән чуарланган, кара төтен белән тулы күкне дә үз эченә ала. Тарихи сугыш чынбарлыкка әверелә һәм шул ук вакытта күпкатлы мәгънәгә ия була бара. Ул хәрби куәтнең рухи көчкә каршы торуын күрсәтә, кешене һәлак итсәң дә, аның рухын сындыру мөмкин түгел. Картинаның төп герое – коралсыз имам Кол Шәриф – хәрби хәрәкәтләрнең үзәгендә сурәтләнгән, баш өстенә ике кулы белән изге Коръән китабын күтәргән (яшел ислам байрагы фонында ул аерылып тора). Ике сакраль предмет та сугышчылар урнашкан композициянең иң югары ноктасын тәшкил итә, ул, мәңгелекне символлаштырып, күккә очы белән юнәлтелгән өчпочмак ясый. Һөҗүм итүчеләрнең бердәм массасы, сөңгеләр белән коралланып, калкулыктагы сакчыларны кысрыклап, астан өскә ыргыла. Шулар арасында ачык төстәге киемнәрдән яшь шәкертләр игътибарны җәлеп итә. Алар остазларын әйләндереп алган. Ярсулы бәрелеш бераз түбәндәрәк: биредә рәссам көрәшүче дошманнарны бар буена сурәтли. Беренче планда, аларның аяклары янында, шәкертнең үле гәүдәсе ята. Һәлак булган исемсез геройга күңелләрдә ихтыярсыз теләктәшлек уяна – ул җиңелгән, әмма буйсынмаган.

Бу картинаның биш йөз ел элек булган хәрби бәрелеш белән ни дәрәҗәдә ярашуын әйтүе кыен. Әмма шунысы төгәл билгеле: имам һәм шагыйрь Кол Шәриф чыннан да яшәгән һәм Казанны саклап вафат булган. Әмма Ф.Г. Халиков ерак үткәндә калган сугышны шундый итеп чагылдырган ки, тамашачы аны «Сөембикәнең хушлашуы» композициясендәге кебек үк чынбарлыкта булган вакыйга дип кабул итә.

Бу картинаның сюжеты Сөембикә ханбикә образын аның тормышының Казан ханлыгын басып алу белән бәйле иң фаҗигалы мизгелләренең берсендә ачуга багышлана. 1551 елда, башкаланы рус гаскәрләре яулап алганчы ук, җирле татар морзалары Сөембикәне Мәскәү патшасына тапшыралар. Шул рәвешле үз дәүләтләренең бәйсезлеген саклап калуга өметләнәләр. Полотнода патшабикәне Мәскәүгә җибәрү вакыты сурәтләнгән. Нәни улы белән Сөембикә утырган арба, патшабикәнең язмышы кебек үк, Казан Кремленең ачык капкасыннан алып чыгучы таш җәелгән юл буйлап аска тәгәри. Аның алга таба юлы, туры һәм күчерелмә мәгънәдә, өстән аска таба юнәлгән. Ул әле патшабикә, әмма инде әсир ителгән, кыйммәтле киемнәрдән, ләкин гади арбада утыра. Ул әле ханзадә Үтәмешгәрәйне кочаклый, яратып күкрәгенә кыса, әмма аның нәни улы белән аерылышу вакыты, Касыйм ханы белән аянычлы туе якынлаша. Тугрылыклы халкы яраткан ханбикәсе белән саубуллашып, дога кылып, баш ия. Атлы арбаны кораллы сакчылар озата бара. Табигать күренеше дә киләчәк кайгы-хәсрәтләр турында хәбәр итә сыман. Нугай далаларыннан килгән Сөембикәгә туган җире кебек якын булган киңлекләр җәйрәп ята.

Ул, хушлашып, аларга соңгы тапкыр моңсу карашын ташлый. Кояш якты елга өстендә асылынып торган күк йөзен каплаган караңгы болытлар артына яшеренергә әзер. Кояшның нурлары, әсир ханбикәне юаткандай, бер генә секундка су өстендә чагылып ала. Ф. Халиков вакыйгада төп катнашучыларны эре планда һәм тәэсирле алым кулланып сурәтли. Ул әсир ханбикәне халык төркеме өстеннән югары күтәреп, рухының ныклыгын ассызыклый.

Шулай итеп, Ф. Халиковның 1990 еллар ахыры – 2000 еллар башы тарихи нәкыше Казан ханлыгының соңгы дәверенә бәйле темаларны сайлау белән характерлана. Ул аларны реалистик планда ачып бирә. Үз геройларын баскан килеш тасвирлап, автор тамашачыларның да полотнода сурәтләнгән вакыйгаларда «катнашуына» ирешә. Зурлыгы буенча масштаблы картиналарда рәссам еш кына күпфигуралы композицияләрне файдалана. Төрле катлау вәкилләренең киемнәренә киенгән төрле яшьтәге икенчел дәрәҗәле геройларны кертү исәбенә тамашачыда чорның дөреслеген тою хисе тудыруга ирешә. Аларның костюм комплекслары тарихи чынбарлыкка таянып, җентекләп эшләнгән. Казан ханлыгы чорының архитектура пейзажын торгызу да ышанычлылык дәрәҗәсен арттыра.

Ф.Г. Халиков үзен мәдәни үзенчәлек кыйммәтенә дан җырлаучы рәссам итеп тоя. Ул киндердә нәкъ менә Россиядәге үзгәртеп кору елларыннан соңгы халыклар аңы өчен хас идеяләрне гәүдәләндерә. Шуңа күрә XVI гасыр Казан ханлыгы каһарманнары һәм шәһәрләре аеруча ачык күрсәтелә. Алар һәр рәссамның җәмгыятьтәге ихтыяҗ һәм өметләргә туры килгән уйлап чыгарылган образлар иҗат итү хокукын чагылдыра. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: аларга һәм рәссам шәхесенә карата кызыксыну тамашачыларның кабул итүенә идеологик компонентның йогынтысы белән аңлатыла. Ул 1990–2010 елларда милли үзаңның күтәрелүендә чагылыш тапты. Хәзерге вакытта, Россиядә милли каршылыклар кимегән чорда, Ф.Г. Халиковның әсәрләре үз сәнгати кыйммәтләрен югалтмыйлар, еракта калган кызыклы һәм мифлаштырылган тарих буенча күрсәтмә материал булып хезмәт итәләр.

Ф.Г. Халиков, авторлык алымнары белән академик башкару манерасын берләштереп, татар милли геройлары образлары галереясын төзи, һәм шуның белән Татарстан рәсем сәнгатендә тарихи жанр үсешенә зур өлеш кертә.

**Әдәбият**

1. *Валеева Д.К., Валеева-Сулейманова Г.Ф., Иорданская Н.И. и др*. Фиринат Халиков. Живопись. Графика. Скульптура. Дизайн. Казань: Заман, 2012. 208 с.: ил.

2. *Халиков А.Х.* Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. Казань: Фэн, 1994. 162 с.: ил.

3. *Хузин Ф.Ш.* Древняя Казань. Казань: Казан: Экс-Пресс плюс, 2005. 152 с.: ил.

4. *Шагеева Р., Магдеев Р.* Фиринат Халиков. М.: Белый город: Воскресный день, 2017. 64 с.: ил.

5. *Шагеева Р.Г.* Халиков Ф.Г. Вечная Казань. Альбом. Казань: Заман, 2005. 192 с.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Герасимова Наталья Владимировна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татаристика һәм мәдәният белеме кафедрасы доценты*

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*кандидат искусствоведения, старший научный сотрудник Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*luda-next@yandex.ru*

***Герасимова Наталья Владимировна,***
*кандидат искусствоведения, доцент кафедры татаристики и культуроведения Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского (Приволжского) федерального университета*

*natal-040183@mail.ru*